Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Күкиавылы 2017 елның 14 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Күкиавыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86, 87, 88 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Күкиавыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проектын 1 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны ачык (гавами) тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча 2 кушымта нигезендә гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча 3 кушымта нигезендә ачык (гавами) тыңлаулар уздыру тәртибен.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу,

гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта оештыру комитеты төзергә (алга таба – оештыру комитеты):

Бәдретдинов Алберт Миннехан улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Башлыгы, эшче төркем рәисе;

Фасхиев Марат Ахкам улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге депутаты, оештыру комитеты әгъзасы.

Галиуллин Айрат Ринат улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлегенең депутаты, оештыру комитеты әгъзасы;

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлауларны 2017 елның 30 апреле көнне 11.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт.

5.Оештыру комитетынаТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча ачык тыңлауларда әйтелгән һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышта кабул итү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы каравына кертүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 нче йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының
2017 елның 14 апрелендәге
3 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күкиавыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Күкиавыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 86, 87, 88 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 апрелендәге 15 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 01.12.2016 №21карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) бирелгән кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
2. 1) 3 өлештәге 19 маддәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1) җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, әлеге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында җирлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләрен төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш»;

2) 2 өлешнең 41 маддәсендәге «хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән» дигән сүзләрне алып ташларга;

3) 44 маддәне түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш белән тулыландырырга:

«2. Җирлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда яки суд карары буенча аңа карата сак астына төрмә яисә аның вәкаләтеннән вакытлыча читләштерү чараларын кулланган очракта аның вәкаләтләрен вакытлыча җирлек башлыгы урынбасары башкара»;

4) 3 өлешнең 86 маддәсендәге икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бирергә: «Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук җирлек Уставына

әлеге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки законнары нигезләмәләрен төгәл яңарту рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очракта, гражданнарның фикер алышуында катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) кирәк түгел.»;

5) 87 маддәне түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш белән тулыландырырга:

«4. Җирлек уставын Федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актлары белән билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законбелән, Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, җирлек уставын Федераль законга Татарстан Республикасы законы белән туры китерү срогы, Тиешле Федераль законның, Татарстан Республикасы Законының үз көченә керү датасын, җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы Карары проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм фикер алышу зарурлыгын исәпкә алып билгеләнә, җирлек Советы утырышларының вакытларыа, җирлек Советының мондый карарын Дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (игълан итү) сроклары, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.».

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Солтан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының яңа редакциясен расларга.

4. Әлеге карар, федераль законнар нигезендә үз көченә керүнең башка сроклары булган пунктларын исәпкә алып, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 нче йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының
2017 елның 14 апрелендәге
3 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советына кертелә:

| № п/п | Маддә, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес (почта) буенча юллана: 422645, ТР, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 12 нче йорт, яисә 8(8-43-61)30581 факсы буенча.
Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ” Күкиавыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты игълан ителгән көннән алып 2019 елның 13 маена чаклы эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422645, ТР, Балык Бистәсе районы, Күкиавылы, Яңа урамы, 12 нче йорт, яисә 8(8-43-61)30581 факсы буенча.
Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәг.кә чаклы ачык тыңлаулар үткәрелү датасына кадәр 7 көннән соңга калмыйча кабул ителәләр.

3. Гражданнар тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки  авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында " карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетына тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Күки  авыл җирлеге башлыгы

А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Күки
авыл җирлеге Советының
2017 елның 14 апрелендәге
3 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар уздыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проекты буенча (алга таба – ачык (гавами) тыңлаулар, тиңдәшле рәвештә карар проекты) ачык (гавами) тыңлаулар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19 маддәсе һәм әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар булып язма рәвештә үзләренең гаризаларын ачык тыңлаулар үткәрелү датасына хәтле җиде көннән дә соңга калмыйча җирлек Советына биргән җирлектә яшәүчеләр тора.

3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмый гына катнашучылар булып җирлекнең һәммә кызыксынучы кешесе торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәг. алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда җирлек Башлыгы яки аның кушуы буенча авыл җирлегенең башка вазифаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10.Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүченең рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан артыкка түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хаклы түгел.

13. Ачык тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны залдан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15. Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык замечание һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә җирлек Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) оештыру комитеты тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19.Ачык тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы

А.М.Бәдретдинов